Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының утыз җиденче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

7 декабрь, 2023 ел № 285

«2021-2026 елларга Питрәч муниципаль районында мәдәниятне үстерү» программасын гамәлгә ашыру барышы турында

Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары «2021-2026 елларга Питрәч муниципаль районында мәдәниятне үстерү» программасын гамәлгә ашыруның барышы турында мәгълүматны тыңлап **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. «Питрәч муниципаль районында 2021-2026 елларга культураны үстерү» программасын (алга таба - Программа) гамәлгә ашыру барышы турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Программа чараларын үтәүнең нәтиҗәлелеге максатларында программа башкаручыларга түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- беренче чираттагы финанслау өчен өстенлекле юнәлешләрне ачыкларга;
- тарихи-мәдәни мирасны саклап калуга һәм популярлаштыруга, эчке туризмны үстерүгә ярдәм итәргә;
- мәдәният өлкәсендәге проектларга социаль партнерларны җәлеп итәргә;
- мәдәни-ял итү учреждениеләре күрсәтә торган хезмәтләрнең сыйфатын арттырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының социаль мәсьәләләр, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният һәм яшьләр эшләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов